Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Сережкино авылында
гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлегенең Яңа Сережкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге Яңа Сережкино авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге Яңа Сережкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балачактан инвалидлар, 1 төркем инвалидлар Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары; тыл хезмәтчәннәреннән тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Яңа Сережкино авылында Урман урамы буенча авыл эчендәге чокырлы юлны ремонтлау;

Яңа Сережкино авылына юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин авылы, Совет ур., 26 йорт-административ бина, Совет ур., 28 йорт - мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 – авыл мәдәният йорты бинасы, Үзәк урам, 15 йорт – мәктәп бинасы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Иванова